СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2022 г. Заинск № 212

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру нигезләмәсен раслау турында» 2021 елның 10 октябрендәге 170 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру нигезләмәсен раслау турында» 2021 елның 10 октябрендәге 170 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына (2021 елның 15 декабрендәге 758 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

5.1. Контроль органның карарларына, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Контроль органның карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) бары тик судка кадәр шикаять белдерелгәннән соң гына, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата судка шикаять бирү очракларыннан тыш, шикаять бирелергә мөмкин.

5.3. Муниципаль торак контроле кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, алар фикеренчә, турыдан-туры бозылган дип уйлаучы контрольдә торучы затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турында карарларга;

б) контроль чаралар актларына;

в) контроль орган вазыйфаи затларының контроль чаралар кысаларында гамәлләренә (гамәл кылмавына).

5.4. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан контроль органына электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып бирелә.

Граждан тарафыннан бирелгән шикаять гади электрон имза йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдә торучы зат тарафыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча, кәгазь чыганакта дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп бирелә.

5.5. Контроль органы карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять контроль органы җитәкчесе тарафыннан карала.

5.6. Контроль органы карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять контрольдә торучы зат үз хокукларының бозылуы турында белгән яки белергә тиеш булган көннән утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогы нигезле сәбәпләр белән үткәреп җибәрелгәндә, шикаять биргән зат үтенечнамәсе буенча әлеге срок контроль орган тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаятьне биргән зат, шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат бирү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенеч булырга мөмкин.
5.7. Шикаятьне теркәгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча контроль орган түбәндәгеләр хакында карар кабул итә:
1) контроль органның шикаять белдерелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында;
2) тикшерү органының шикаять белдерелә торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында.
Шикаять белдерелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турында үтенечнамә буенча карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә мәгълүмат шикаять биргән затка җибәрелә.
5.8. Шикаять үз эченә алырга тиеш:
1) тикшерү органының исеме, карар һәм (яисә) гамәл башкаруга (гамәл кылмауга) дәгъва кылына торган вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);
2) гражданның фамилиясе, исемен, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлек башкару урыны) турында белешмәләр, яисә мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, йә ышанычнамә реквизитлары һәм шикаятьне ышанычнамә буенча тапшыручы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча кабул ителгән карарны алуның теләгән ысулы;
3) шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган контроль органның һәм (яисә) аның вазыйфаи затының дәгъвалана торган карары турында белешмәләр;
4) мөрәҗәгать итүченең контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән нигезләре һәм дәлилләре. Гариза бирүче дәлилләрне раслый торган документларны (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшыра ала;
5) шикаять биргән затның таләпләре;
6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, шикаять бирелгән контроль (күзәтчелек) чараларның Бердәм реестрында контроль чараны исәпкә алу номеры.
Шикаятьтә контроль органы вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата янаулар, цензурасыз сүзләр яисә мыскыллаулы гыйбарәләр булырга тиеш түгел.
Шикаять, тиешле хокук бирелгән очракта, «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә контрольдә тотыла торган затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан бирелергә мөмкин.
Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгатьчелек вәкиленең, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы эшкуарлар

хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең шикаять предметына караган позициясе дә теркәлергә мөмкин.
Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, аның җәмәгатьчелек вәкиле, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил позициясенә контроль орган тарафыннан җавап шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.
5.9. Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаятьне алган вакыттан биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә, әгәр:
1) шикаять әлеге нигезләмәнең 5.6 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы чыкканнан соң бирелсә һәм аны торгызу турында яисә шикаять бирүнең билгеләнгән срогын торгызуга үтенечнамәне үз эченә алмаса;
2) шикаять бирүгә каралган вакытны торгызу турында үтенечне канәгатьләндерүдән баш тартылса;
3) шикаять буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза кергәндә;
4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары булса;
5) элегрәк контроль органга шул ук контрольдә тотыла торган заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелсә;
6) шикаятьтә контроль органы вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата янаулар, цензурасыз сүзләр яисә мыскыллаулы гыйбарәләр булса;
7) элегрәк әлеге контрольдә тотылучы затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук мәсьәлә буенча шикаятьне карап тикшерүдән баш тартылган һәм яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәгән;
8) шикаять тиешле булмаган контроль органына тапшырылган;
9) Россия Федерациясе законнарында контроль орган карарларына карата шикаять бирүнең суд тәртибе генә каралган.
Әлеге пунктның 3-8 бүлекчәләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.
5.10. Шикаятьне карауга вәкаләтле контроль органының вазыйфаи заты шикаятьне караганда, шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләр һәм документлар бәйле очраклардан тыш, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасыннан файдалана.
Контроль орган судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләр тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне контроль орган җитәкчесе тарафыннан карау, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасыннан файдаланмыйча, дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп башкарыла.
5.11. Шикаять контроль орган тарафыннан теркәлгәннән соң егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.
Аерым очракларда күрсәтелгән орган тарафыннан вакыт озайтылырга мөмкин, әмма ул егерме эш көненнән дә артып китә алмый.
5.12. Контроль орган шикаять биргән контрольдә торучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар соратырга хокуклы.
Контрольдә тотылучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны сорату җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.
Шикаятьне карау шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында запрос җибәрелгәннән алып, аларны контроль орган алган вакытка кадәр, әмма сорату җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артмаган срокта туктатыла.
Контрольдә тотылучы заттан шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар алынмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.
Шикаять биргән контрольдә тотылучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга караган оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.
Шикаятьне биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче, үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.
5.13. Вазыйфаи затның шикаять белдерелә торган карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавына) карата кабул ителгән карарның һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген исбатлау бурычы контроль органына йөкләнә.
5.14. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:
1) шикаятьне канәгатьләндерми;
2) тикшерү органы карарын тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыгара;
3) тикшерү органы карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;
4) контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.
5.15. Кабул ителгән карарны нигезләүне үз эченә алган контроль органы карары, аны башкару срогы һәм тәртибе, кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, контрольдә тотыла торган затның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинетында урнаштырыла.

Дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау йомгаклары буенча контроль орган карары контрольдә тотылучы затка кәгазь чыганакта, кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә, дәүләт сере яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп җибәрелә.».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**